# КАРАР

**06 апрель 2024 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегенең Яңа Ашыт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 14 ноябрендәге 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегенең Яңа Ашыт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 , 56 статьяларына, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кенәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Яңа Ашыт авылында 2024 елның 06 апрелендә «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегенең Яңа Ашыт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә халык җыены беркетмәсе тәзелде:

"Сез 2024-нче елда Яңа Ашыт авылы территориясендә яшәгән урында теркәлгән һәр олы кешедән 600 сум күләмендә үз-үзегезгә салым салырга ризалашасызмы, 1-нче төркем инвалидларын исәпкә алмаганда, гражданнар 80 яшь, инвалид балалар, сугыш ветераннары, Чернобыль атом электр станциясендә булган аварияне бетерүдә катнашучылар, түләү күләме 300 сум үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы? Түбәндәге эш:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам-юл челтәрендәге юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю Яңа Ашыт авылы: Җиңү урамы (100 м); Вахитов урамы (50 м)).

« ЭЙЕ» «КАРШЫ»»

Гражданнарның җыен (йомгаклау беркетмәсе) беркетмәсе нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 87 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 46 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 46 кеше тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Яңа Ашыт авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип.

2. "Сез 2024-нче елда Яңа Ашыт авылы территориясендә яшәгән урында теркәлгән һәр олы кешедән 600 сум күләмендә үз-үзегезгә салым салырга ризалашасызмы, 1-нче төркем инвалидларын исәпкә алмаганда, гражданнар 80 яшь, инвалид балалар, сугыш ветераннары, Чернобыль атом электр станциясендә булган аварияне бетерүдә катнашучылар, түләү күләме 300 сум үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы? Түбәндәге эш:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам-юл челтәрендәге юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю Яңа Ашыт авылы: Җиңү урамы (100 м); Вахитов урамы (50 м) кабул ителгән».

3. Җыенның нәтиҗәләрен ТР, Арча районы, Яңа Ашыт авылы, Вахитов урамы, 18 нче йорт адресы буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://arsk.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга кирәк: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин